СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

09.04.2026

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-4

с. Введенская Слобода

№6-34

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2026 елның 1 кварталында үтәлеше турында

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозовның 2026 елның 1 кварталында Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетын үтәү турында докладын тыңлап һәм фикер алышып,

Югары Ослан муниципаль районының
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2026 елның 1 кварталында бюджетын үтәү турында отчетны расларга (1нче куштама).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Советының 09.04.2026 ел №6-34
карарына

1нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2026 елның 1 кварталында бюджетын үтәү турында отчет»

Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2026 елда бюджетын үтәү 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законын үтәү һәм гамәлгә кую шартларында башкарыла.

Введенский Бистәсе авыл җирлегенең бюджеты үзгәртүләр һәм өстәмәләр исәбенә, керемнәр буенча 23 560,6 мең сумга расланган.

Авыл җирлегенең бюджеты 01.04.2026 елга керем өлеше буенча 28 501,9 мең сумга үтәлгән.

Җирлек бюджеты керемнәренең төп өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашты:

- физик затларның керем салымы - 25% үтәлгән (1320,0 мең сум план буенча 330,02 мең сумга үтәлгән);
- физик затларның милек салымы – бары тик 3% үтәлгән (1637,2 мең сум план буенча 57,4 мең сум);
- җир салымы – 132% үтәлгән (18420,4 мең сум план буенча 24299,2 мең сум), алардан оешмалардан 24253,6 мең сум һәм халыктан 46,6 мең сум кергән;
- милекне арендага тапшырудан керем - 1,2 мең сум;
- туристлык салымы – 3473,7 мең сум, 1538,0 сум план буенча
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем – 0 мең сум, 371,8 мең сум план буенча;

Башка салым булмаган керемнәр:
- үзара салым - 234,5 мең сум.

Бюджетның төгәлләштерелгән чыгым өлеше (Татарстан Республикасы һәм Югары Ослан муниципаль районы бюджетларына күчерелгән акчаларны исәпкә алып, үзара салым акчаларыннан башка) 25 293,3 мең сум тәшкил иткән, асылда чыгым 20 143,6 мең сум күләмендә 79% ка үтәлгән.

Чыгымнар түбәндәге максатларга башкарылган:
• идарә 773,8 мең сум;
• мәдәният 289,2 мең сум;
• 526,8 мең сум, шуның:
- урамнарны яктырту 280,9 мең сум,
• юлларны карап тоту 1774,2 мең сум,
• коммуналь хезмәтләр өлкәсендәге гамәлләр (су суырту) 13,8 мең сум;
• башка төзекләндерү-155,2 мең сум

ТР бюджетына тискәре трансфертлар 710,5 мең сум һәм районга бюджетара трансфертлар 15924,4 мең сум.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов